| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 29.04.2025 | г. Зеленодольск | № 480 |

Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында» 2020 елның 7 сентябрендәге 516 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 23 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 17 декабрендәге 118 номерлы, 2022 елның 16 сентябрендәге 198 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 236 номерлы, 2023 елның 16 февралендәге 253 номерлы, 2024 елның 30 маендагы 396 номерлы, 2024 елның 5 августындагы 417 номерлы, 2024 елның 31 октябрендәге 420 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында» 2020 елның 7 сентябрендәге 516 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 23 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 17 декабрендәге 118 номерлы, 2022 елның 16 сентябрендәге 198 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 236 номерлы, 2023 елның 16 февралендәге 253 номерлы, 2024 елның 30 маендагы 396 номерлы, 2024 елның 5 августындагы 417 номерлы, 2024 елның 31 октябрендәге 420 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)(алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 маеннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) икенче абзацта «42 541 (кырык ике мең биш йөз кырык бер) сум һәм 141 312 (йөз кырык бер мең өч йөз унике) сум күләмендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләрен «46 796 (кырык алты мең җиде йөз туксан алты) сум һәм 171 949 (бер йөз җитмеш бер мең тугыз йөз кырык тугыз ) сум күләмендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләренә алмаштырырга, «0,78» саннарын «0,6» санына алмаштырырга;

1.3) өченче абзацта «38 286 (утыз сигез мең ике йөз сиксән алты) сум һәм 62 834 (алтмыш ике мең сигез йөз утыз дүрт) сум күләмендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләрен «42 115 (кырык ике мең бер йөз унбиш) сум һәм 78 195 (җитмеш сигез мең бер йөз туксан биш сум күләмнендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләренә алмаштырырга;

1.4) дүртенче абзацта «38 286 (утыз сигез мең ике йөз сиксән алты) сум күләмендә һәм 62 834 (алтмыш ике мең сигез йөз утыз дүрт) сум күләмендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләрен «42 115 (кырык ике мең бер йөз йөз унбиш) сум һәм 78 195 (җитмеш сиксән мең йөз туксан биш) сум акүләмендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләренә алмаштырырга;

1.5) бишенче абзацта «28 817 (егерме сигез мең сигез йөз унҗиде) сум һәм 31 855 (утыз бер мең сигез йөз илле биш) сум күләмендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләрен «31 699 (утыз бер мең алты йөз туксан тугыз) сум һәм 40 488 (кырык мең дүрт йөз сиксән сигез) сум күләмендә ай саен акчалата бүләкләү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 маеннан» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «42 541 (кырык ике мең биш йөз кырык бер) сум күләмендә» сүзләрен «46 796 (кырык алты мең җиде йөз туксан алты) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2.3) өченче абзацта «38 286 (утыз сигез мең ике йөз сиксән алты) сум күләмендә» сүзләрен «42 115 (кырык ике мең бер йөз унбиш) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2.4) дүртенче абзацта «38 286 (утыз сигез мең ике йөз сиксән алты) сум күләмендә» сүзләрен «42 115 (кырык ике мең бер йөз унбиш) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2.5)бишенче абзацта «28 817 (егерме сигез мең сигез йөз унҗиде) сум күләмендә» сүзләрен «31 699 (утыз бер мең алты йөз туксан тугыз) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

3). 3 пунктта «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 маеннан» сүзләренә алмаштырырга;

4). «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре» кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2025 елның 29
апрелендәге 480 номерлы карарына
кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфалары атамасы** | **Айлык вазыйфаи окладының күләме (сум)** |
|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | 46 167 |
| Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | 42 628 |
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, | 41 859 |
| «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МУ, «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы » МУ җитәкчеләре | 41 705 |
| «Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МУ, «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы »МУ җитәкчеләре урынбасарлары | 37 857 |
| Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 38 781 |

| | |
|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының, Зеленодольск муниципаль районының башка җирле үзидарә органының мөстәкыйль бүлек (идарә) начальнигы, башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 31 702 |
| Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының, Зеленодольск муниципаль районының башка җирле үзидарә органының мөстәкыйль бүлек (идарә) начальнигы урынбасары, башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы киңәшчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе киңәшчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты идарә составындагы бүлек начальнигы | 26 162 |
| Сектор мөдире | 24 315 |
| Баш белгеч | 23 392 |
| Әйдәп баручы белгеч | 22 007 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 19 698 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) Порталында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**